ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О регулировании отдельных вопросов в сфере реализации прав граждан на приобретение жилья экономического класса в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
22 марта 2018 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 28 декабря 2012 года № 95-ЗРТ «О регулировании отдельных вопросов в сфере реализации прав граждан на приобретение жилья экономического класса в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 12 (II часть); 2014, № 3; 2015, № 3, № 7 (I часть); 2016, № 3; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 76 (часть I) следующие изменения:

1) в наименовании слова «жилья экономического класса» заменить словами «стандартного жилья»;

2) статью 1 изложить в следующей редакции:
«Статья 1. **Общие положения**

Настоящий Закон в соответствии с Федеральным законом от 24 июля 2008 года № 161-ФЗ «О содействии развитию жилищного строительства» (далее – Федеральный закон) устанавливает правила формирования списков граждан, имеющих право на приобретение жилых помещений в многоквартирных домах и (или) жилых домах блокированной застройки, индивидуальных жилых домов, которые соответствуют условиям отнесения к стандартному жилью (далее –

стандартное жилье), построенных или строящихся на земельных участках единого института развития в жилищной сфере (далее – единый институт развития), переданных в безвозмездное пользование или аренду для строительства стандартного жилья, для комплексного освоения территории, в рамках которого предусматривается в том числе строительство стандартного жилья (далее – безвозмездное пользование или аренда для строительства стандартного жилья), а также в аренду для строительства в минимально требуемом объеме стандартного жилья, для комплексного освоения территории, в рамках которого предусматриваются в том числе строительство в минимально требуемом объеме стандартного жилья и иное жилищное строительство (далее – аренда для строительства в минимально требуемом объеме стандартного жилья), и порядок, в частности очередность, включения указанных граждан в списки граждан, имеющих право на приобретение стандартного жилья, построенного или строящегося на земельных участках единого института развития, переданных в безвозмездное пользование или аренду для строительства стандартного жилья, а также в аренду для строительства в минимально требуемом объеме стандартного жилья (далее – список), и в соответствии с Федеральным законом от 21 июля 2014 года № 224-ФЗ «О внесении изменений в Градостроительный кодекс Российской Федерации и отдельные законодательные акты Российской Федерации» регулирует отдельные вопросы, связанные с реализацией прав граждан на приобретение стандартного жилья.»;

3) в статье 2:

а) в пункте 6 части 1 слова «жилья экономического класса» заменить словами «стандартного жилья»;

б) в части 2:

в пункте 2 слова «жилья экономического класса» заменить словами «стандартного жилья»;

в пункте 3 слова «жилья экономического класса» заменить словами «стандартного жилья»;

в пункте 5 слова «жилья экономического класса» заменить словами «стандартного жилья»;

4) в части 2 статьи 3:

а) в пункте 1 слова «соответствующих условиям отнесения к жилью экономического класса» заменить словами «являющихся стандартным жильем»;

б) в пункте 3:

в подпункте «а» слова «соответствующих условиям отнесения к жилью экономического класса» заменить словами «являющихся стандартным жильем»;

в подпункте «б» слова «жилья экономического класса» заменить словами «стандартного жилья»;

5) в наименовании статьи 4 слова «жилья экономического класса» заменить словами «стандартного жилья»;

6) в наименовании статьи 5 слова «жилья экономического класса» заменить словами «стандартного жилья»;

7) в статье 6:

а) в наименовании слова «жилье экономического класса» заменить словами «стандартное жилье»;

б) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. В целях формирования списка граждан, согласившихся приобрести стандартное жилье на условиях, установленных протоколом о результатах аукциона, уполномоченный орган местного самоуправления в течение пяти рабочих дней с даты заключения договора безвозмездного пользования земельными участками единого института развития для строительства стандартного жилья или их аренды, договора аренды земельных участков единого института развития для строительства в минимально требуемом объеме стандартного жилья публикует в официальных средствах массовой информации и размещает на официальном сайте муниципального образования в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» информационное сообщение о результатах аукциона с указанием сведений, содержащихся в протоколе о результатах такого аукциона, а также срока направления согласия гражданина на заключение договора.»;

в) в части 2 слова «жилья экономического класса» заменить словами «стандартного жилья»;

г) первое предложение части 3 изложить в следующей редакции:

«Список граждан, согласившихся приобрести стандартное жилье на условиях, установленных протоколом о результатах аукциона, формируется уполномоченным органом местного самоуправления муниципального образования, на территории которого расположен земельный участок единого института развития, переданный по договору безвозмездного пользования или аренды для строительства стандартного жилья, договору аренды для строительства в минимально требуемом объеме стандартного жилья, из числа граждан, заявления которых учтены в муниципальных образованиях согласно представленным перечням, с сохранением хронологического порядка регистрации заявлений граждан.»;

д) в абзаце первом части 4 слова «приобрести жилье экономического класса» заменить словами «приобрести стандартное жилье», слова «жилых помещений в жилье экономического класса» заменить словами «жилых помещений, являющихся стандартным жильем»;

е) в части 6 слова «жилья экономического класса» заменить словами «стандартного жилья»;

ж) в подпункте $1^1$ пункта 1 части 8 слова «жилья экономического класса» заменить словами «стандартного жилья».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
11 апреля 2018 года
№ 19-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 22 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 2012 елның 28 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 7 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 76 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә “эконом класслы торак” сүзләрен “стандарт торак” сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Әлеге Закон “Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында” 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә торак өлкәсендә бердәм үсеш институтының (алга таба – бердәм үсеш институты) стандарт торак төзү өчен, территорияне комплекслы, шул исәптән стандарт торак төзелеше дә каралган үзләштерү өчен түләүсез файдалануга яисә арендага (алга таба – стандарт торак төзелеше өчен түләүсез файдалану яисә аренда), шулай ук стандарт торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен, территорияне комплекслы, шул исәптән стандарт торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү һәм башка торак төзелеше дә каралган үзләштерү өчен арендага (алга таба – стандарт торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү

өчен аренда) тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән йә төзелеп килүче стандарт торакка кертү шартларына туры килә торган күпфатирлы йортларда һәм (яисә) блоклы төзелә торган торак йортларда торак урыннар, индивидуаль торак йортлар (алга таба – стандарт торак) сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү кагыйдәләрен һәм күрсәтелгән гражданнарны бердәм үсеш институтының стандарт торак төзү өчен түләүсез файдалануга яисә арендага, шулай ук стандарт торакны минималь таләп итеелә торган күләмдә төзү өчен арендага тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче стандарт торак сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләренә (алга таба – исемлек) кертү тәртибен, аерым алганда, чиратлылыгын билгели, "Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2014 елның 21 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның стандарт торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга сала.";

3) 2 статьяда:

а) 1 өлешнең 6 пунктында "эконом класслы торак" сүзләрен "стандарт торак" сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә:

2 пунктта "эконом класслы торак" сүзләрен "стандарт торак" сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта "эконом класслы торак" сүзләрен "стандарт торак" сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта "эконом класслы торак" сүзләрен "стандарт торак" сүзләренә алмаштырырга;

4) 3 статьяның 2 өлешендә:

а) 1 пунктта "эконом класслы торакка кертү шартларына туры килерлек" сүзләрен "стандарт торак саналган" сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта:

"а" пунктчасында "эконом класслы торакка кертү шартларына туры килерлек" сүзләрен "стандарт торак саналган" сүзләренә алмаштырырга;

"б" пунктчасында "эконом класслы торак" сүзләрен "стандарт торак" сүзләренә алмаштырырга;

5) 4 статьяның исемендә "эконом класслы торак" сүзләрен "стандарт торак" сүзләренә алмаштырырга;

6) 5 статьяның исемендә "эконом класслы торак" сүзләрен "стандарт торак" сүзләренә алмаштырырга;

7) 6 статьяда:

а) исемендә "эконом класслы торак" сүзләрен "стандарт торак" сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә билгеләнгән шартларда стандарт торак сатып алуга ризалык биргән гражданнарның исемлеген төзү максатларында вәкаләтле җирле үзидарә органы стандарт торак төзелеше өчен бердәм үсеш институтының җир кишәрлекләрен түләүсез файдалану яисә арендалау шартнамәсе, стандарт торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен бердәм үсеш институтының җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсе төзегән датадан биш эш көне эчендә, мондый аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәдәге белешмәләрне, шулай ук шартнамә төзүгә гражданның ризалыгын җибәрү срогын күрсәтеп, аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмати хәбәрне рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгара һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтына урнаштыра.”;

в) 2 өлештә “эконом класслы торак” сүзләрен “стандарт торак” сүзләренә, “эконом класслы торакны” сүзләрен “стандарт торакны” сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә билгеләнгән шартларда стандарт торак сатып алуга ризалык биргән гражданнар исемлеге бердәм үсеш институтының стандарт торак төзү өчен түләүсез файдалану яисә арендалау шартнамәсе, стандарт торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен арендалау шартнамәсе буенча тапшырылган җир кишәрлеге урнашкан территориядәге муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан, гражданнарның гаризаларын теркәүнең хронологик тәртибе сакланган килеш, бирелгән исемлекләр нигезендә муниципаль берәмлекләрдә гаризалары исәпкә алынган гражданнар арасыннан төзелә.”;

д) 4 өлешнең беренче абзацында “эконом класслы торак сатып алуга” сүзләрен “стандарт торак сатып алуга” сүзләренә алмаштырырга, “эконом класслы торакта торак урыннарының” сүзләрен “стандарт торак саналган торак урыннарының” сүзләренә алмаштырырга;

е) 6 өлештә “эконом класслы торак” сүзләрен “стандарт торак” сүзләренә алмаштырырга, “эконом класслы торакны” сүзләрен “стандарт торакны” сүзләренә алмаштырырга;

ж) 8 өлешнең 1 пунктындагы $1^1$ пунктчасында “эконом класслы торакның” сүзләрен “стандарт торакның” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 11 апрель
№ 19-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН